ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.03.2019 с. Большие Кайбицы № 151

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда тикшерүнең Административ регламентын раслау турында

2008нче елның 26нчы декабрендә чыккан 294-ФЗ номерлы «Юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең дәүләт контроле (күзәтүе) һәм муниципаль контроль башкарганда хокукларын саклау турында» Федераль законы, Татарстан Республикасының 2015нче елның 13нче октябрендә чыккан 83-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру турында» Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2010нчы елның 12нче ноябрендә 11нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру тәртибе Нигезләмәсе белән Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР КЫЛА:

1.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда тикшерүнең Административ регламентын расларга (Кушымта №1).

2.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2010нчы елның 15нче декабрендә чыккан 526нчы номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда тикшерүнең Административ регламентын раслау турында » (2016нчы елның 11нче февралендә кертелгән үзгәрешләр белән) карарын гамәлдән чыккан дип санарга.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм информацион-телекоммуникацион

Интернет челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнашкан "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **А.Н.Макаров**

Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2019нчы елның
«29»нчы мартында чыккан 151нче
номерлы карарына Кушымта №1

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда тикшерүнең Административ регламенты**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда тикшерүнең Административ регламенты (алга таба - административ регламент) Кайбыч муниципаль районы территориясендә милек формасының нинди төре булуына карамастан җирләрне куллануны тикшерүнең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын үстерү максатында эшләнә һәм муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда аны үткәрү вакытын, дәвамчанлыгы шартларын, шулай ук муниципаль җир контролен гамәлгә куйганда вазыйфаи затларның эшен үтәү (үтәмәү ) турында шикаять бирү тәртибен билгели.

1.2. Кайбыч муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру түбәндәгеләргә таянып башкарыла:
- Россия Федерациясе Конституциясе;
- Россия Федерациясе Җир кодексы ( 25.10.2001 №136-ФЗ);
- “Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында“ Федераль законы (25.10.2001 №137-ФЗ);
- Россия Федерациясе административ хокук бозулар Кодексы (30.12.2001 №195-ФЗ);
- «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законы (06.10.2003 №131-ФЗ);
- «Юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең дәүләт контроле (күзәтүе) һәм муниципаль контроль башкарганда хокукларын саклау турында» Федераль законы (26.12.2008 №294-ФЗ);
- РФ Хөкүмәтенең 2016нчы елның 18нче апрелендә чыккан 323нче номерлы «Дәүләт күзәтү органнары, муниципаль тикшерү органнары яисә Дәүләт күзәтү органнары, муниципаль тикшерү органнарына буйсынучы җирле үзидарә органнарының алар карамагында ведомствоара мәгълүматый тәэсир итешү чикләрендәге бу документлар һәм (яки) мәгълүмат бушлай запрос җибәрү һәм документлар һәм (яки) мәгълүмат алу, шул исәптән электрон формада алу турында” карары;

-РФ Хөкүмәтенең 2016 елның 19 апрелендәге 724номерлы «Тикшерү оештыру һәм үткәрү вакытында дәүләт контроле (күзәтүе) органнары, муниципаль контроль (күзәтү) органнары тарафыннан ведомствоара мәгълүматый мөнәсәбәтләр чикләрендә башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яки бу документлар һәм (яки) мәгълүмат алып була торган башка оешмалардан сорала һәм алына торган документлар һәм (яки ) мәгълүмат исемлеген раслау турында » боерыкнамәсе;

-муниципаль җир контроле органыннан ведомствоара мәгълүмати үзара эшчәнлек кысаларында башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан кергән яисә дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалар карамагындагы документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән танышу;

-Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2015 елның 13 октябрендәге 83-ТРЗ санлы Законы (алга таба – Татарстан Республикасының 83-ТРЗ санлы Законы);

- Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы;

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы карары белән 2010нчы елның 12нче ноябрендә расланган 11нче номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә кую тәртибе турындагы Нигезләмә.

1.3. Кайбыч муниципаль районы җир һәм милек мөнәсәбәтләре Палатасы (алга таба - Палата) тарафыннан муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру оешмаларны тикшерүләр, милек хуҗалары булган шәхси эшкуарлар, физик затлар , җир белән кулланучылар, җир хуҗалары һәм Кайбыч муниципаль районы территориясендә булган җирләрне арендалаучыларга карата аларның оештыру-хокукый формасы һәм милек формасына карамастан башкарыла.

Кайбыч муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыручылар Палатаның вазыйфаи затлары.

1.4. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда Палата җир контролен гамәлгә ашыручы махсус вәкаләтле дәүләт органнары , кызыксынучы башкарма хакимият органнары, иҗтимагый берләшмәләр, шулай ук гражданнар белән мөнәсәбәттә торып эшли һәм түләүсез шартларда , шул исәптән электрон формада РФ Хөкүмәте исемлеге нигезендә документлар һәм мәгълүмат сорый һәм ала (җирле үзидарә органнарыннан, алар карамагында ведомствоара мәгълүматый тәэсир итешү чикләрендәге бу документлар һәм (яки) мәгълүмат).

1.5. Сорала торган документлар һәм (яки) мәгълүматта , закон белән саклана торган сер яки салым турында мәгълүмат булса, ведомствоара мәгълүматый тәэсир итешү чикләрендә бу белешмәләр юридик затлар, шәхси эшмәкәрләрнең һичшиксез үтәлергә тиешле шартлары федераль закон белән каралган булса гына мөмкин.

1.6. Ведомствоара мәгълүматый тәэсир итешү чикләрендә документ һәм мәгълүматларны тапшыру, аларны ачу, шул исәптән танышу канунчылык белән

каралган очракларда дәүләт сере һәм башка закон белән саклана торган серне Россия Федерациясе законнарындагы шартларны үтәп башкарыла.

1.7. Муниципаль җир контроле нәтиҗәсе булып Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары, “Кайбыч муниципаль районы” муниципаль берәмлеге хокукый актлары белән күрсәтелгән шартларны бозуны ачыклау, аларны юкка чыгаруны тәэмин итү, яисә җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә кимчелекләр булмауны ачыклау тора.

## II. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру тәртибенә таләпләр

2.1. Тикшерү үткәрү турында хәбәр итү тәртибе.

2.1.1. Кайбыч муниципаль районында планлы тикшерүләр Палата Җитәкчесе раслаган еллык план белән карала, һәм кызыксынган затларга http://kaybici.tatarstan.ru адресы буенча Кайбыч муниципаль районы сайтында урнаштырып җиткерелә.

Юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик зат Палата тарафыннан өч көн алдан планлы тикшерү үткәрү һәм аны башлау турында турында Палата җитәкчесе, аның урынбасары планлы тикшерүләр үткәрү турында чыгарган боерык копиясен җибәреп хәбәр ителә. Әлеге боерыкның күчермәсе тапшыру турында хәбәрнамәле заказлы почта хаты һәм (яки) юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик затның электрон почтасы юридик затларның дәүләт реестрында булса, яисә дәүләт контроле (тикшерүе ) органына юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан җиткерелгән булса, квалификацияле көчәйтелгән электрон имзалы документ белән электрон адреска җибәрелә, яки башка уңайлы ысул белән хәбәр ителә.

2.1.2. Планнан тыш тикшерү турында, «Юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең дәүләт контроле (күзәтүе) һәм муниципаль контроль башкарганда хокукларын саклау турында» Федераль законның 2нче бүлеге 2нче өлеше 10нчы статьясында карлаган очраклардан тыш, тикшерүче вазыйфаи зат тикшерeләчәк затка кимендә 24 сәгать алдан хәбәр итә.

2.1.3. Кайбыч муниципаль районында планлы муниципаль җир тикшерүләре турында Палатага язма хат аша яки Палата Җитәкчесенә шәхси кабул итүгә килеп белеп була.

Палата Җитәкчесенең шәхси кабул итүе гражданнарны кабул итү графигы нигезендә алдан язылу буенча оештырыла.

Язма мөрәҗәгатькә җавап Кайбыч муниципаль районында җир тикшерүләре буенча җаваплы затлар тарафыннан канунчылык белән билгеләнгән тәртиптә бирелә.

Палатаның Юридик адресы: 422330. Татарстан Республикасы , Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар урамы, 7нче йорт.

Хәбәрләшү телефоннарыы: 2-12-15 (кабул итү/факс), 2-12-15.

Эш режимы : дүшәмбе – җомга 8.00 дән 17.00гә кадәр , тәнәфес - 12.00дән 13.00гә кадәр , ял көннәре - шимбә, якшәмбе.

Кайбыч муниципаль районы сайты адресы: http:// kaybici.tatarstan.ru

2.2. Тикшерү өчен кирәкле документлар

2.2.1. Планлы (документар или күчмә) тикшерү Палата Җитәкчесе раслаган еллык тикшерүләр үткәрү планына нигезләнеп , Палата Җитәкчесенең яки урынбасарының планлы (документар или күчмә) тикшерү үткәрү турында боерыгы нигезендә үткәрелә.

2.2.2. Планнан тыш (документар или күчмә) тикшерү Палата Җитәкчесенең яки урынбасарының планнан тыш (документар или күчмә) тикшерү үткәрү турында боерыгы нигезендә үткәрелә.

2.2.3. Планнан тыш тикшерү предметы булып юридик зат,шәхси эшмәкәр тарафыннан эшчәнлеген гамәлгә ашырганда мәҗбүри шартларны саклау, муниципаль хокукый актлар белән күрсәтелгән шартларны саклау, дәүләт контроле органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан бирелгән күрсәтмәне үтәү, гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләргә), музей предметларына һәм Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, милли китапханә фонды составына кертелгән аеруча тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга зыян килү куркынычы янау, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы янау һәм боларны юкка чыгару;

Планнан тыш тикшерү үткәрүнең нигезе:

1) юридик зат, шәхси эшкуарга муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән, мәҗбүри шартларны үтәүдә ясалган кимчелекләрне бетерү буенча аладан бирелгән күрсәтмәнең вакыты чыгу;

1.1) юридик зат, шәхси эшкуардан муниципаль җир контроле органына, әгәр юридик зат, шәхси эшкуарны мондый планнан тыш тикшерү хокукый статус , махсус рөхсәт (лицензия), рөхсәт (килешү) бирү кагыйдәләре белән каралган булса, аерым эшчәнлек төрләре буенча хокукый статус , махсус рөхсәт (лицензия) килү яки башка юридик әһәмияткә ия эшчәнлеккә рөхсәт (килешү) алуга гариза;

2) муниципаль җир контроле органы вазыйфаи затының юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр катнашыннан тыш гражданннар мөрәҗәгате яки гаризасы, дәүләт хакимияте органы, информации җирле үзидарә органы, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган түбәндәге мәгълүматлар буенча буенча үткән алдан тикшерү чаралары нәтиҗәләре анализы нәтиҗәсе буенча дәлилле тәкъдиме:

а) гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләргә), музей предметларына һәм Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, милли китапханә фонды составына кертелгән аеруча тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга зыян килү

куркынычы янау, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы янау һәм боларны юкка чыгару куркынычы янау;

ә) гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга,үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләргә), музей предметларына һәм Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей коллекция-ләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, милли китапханә фонды составына кертелгән аеруча тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга зыян килү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу;

б) хокуклары бозылган гражданнар мөрәҗәгать иткән очракта, кулла-нучыларның хокуклары бозылу (кулланучыларның хокукларын саклау өлкәсендә федераль дәүләт күзәтүе үткәрүче органга хокуклары бозылган гражданнар ,үз хокукларны кире кайтаруны (торгызуны) сорап юридик зат, шәхси эшкуарга мөрәҗәгать иткән һәм бу таләп каралмаган яки үтәлмәгән очракта );

в) прокурорның прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча тикшерү кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү таләбе.

Планнан тыш тикшерү үткәрүнең нигезе булып юридик зат, шәхси эшкуарга муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән, мәҗбүри шартларны үтәүдә ясалган кимчелекләрне бетерү буенча алдан бирелгән күрсәтмәнең вакыты чыгу торса, мондый тикшерүнең предметы булып дәүләт контроле (күзәтүе) органы яки муниципаль контроль органы тарафыннан бирелгән күрсәтмәне үтәү генә тора ала. Гариза бирүче үзенең язма мөрәҗәгатендә мәҗбүри тәртиптә я язма мөрәҗәгать җибәрелә торган җир контроле башкаручы орган атамасын, я тиешле вазыйфаи затның фамилиясен, исемен, әтисенең исемен, я тиешле затның вазыйфасын, шулай ук фамилиясен, исемен, әтисенең исемен, җаваплар , мөрәҗәгать кире адреслану турында хәбәрнамә, җибәрелергә тиешле почта адресын яза,тәкъдим, гариза яки шикаять эчтәлегенә аңлатма бирә,шәхси имзасын һәм датаны куя.

Үз дәлилләрен раслау кирәк булган очракта, гариза бирүче язма мөрәҗәгатенә өстәп документлар һәм материаллар яисә аларның копияләрен куя.

2.2.4. Муниципаль җир контроле органына мөрәҗәгать итүче затны ачыклау мөмкинлеге булмаган, шулай ук Әлеге Нигезләмәнең 22нче пунктында каралган фактлар турында мәгълүматлар булган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып саналмый. Әлеге Нигезләмәнең 22нче пункты нигезендә мөрәҗәгатьтә яки гаризада бәян ителгән мәгълүмат планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып саналган очракта, муниципаль җир контроле органының вазыйфаи заты, әгәр аңарда мөрәҗәгать яки гаризаның авторлыгында нигезле шикләнүләр булса, мөрәҗәгать иткән затны ачыклау өчен ул тиешле чаралар күрергә тиеш. Электрон документлар рәвешендә җибәргән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, гариза бирүче тарафыннан аның бердәм идентификация һәм аутентификация системасында мәҗбүри

авторизацияне күздә тоткан мәгълүмат-коммуникация технологияләрен кулланып җибәрелгән очракта, алар планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып санала.

Әлеге Нигезләмәнең 22нче пунктында каралган мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны, мәгълүматны караганда, элек кергән шундый мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны карау нәтиҗәләре, шулай ук тиешле юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга карата элек үткәрелгән контроль чараларның нәтиҗәләре исәпкә алынырга тиеш.

Мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куйган зат турында дөрес мәгълүмат булмаганда, мәҗбүри таләпләрне бозу турында муниципаль җир контроле органының вазыйфаи затлары тарафыннан кергән мәгълүматны алдан тикшерү үткәрелә. Алдан тикшерү үткәрү барышында, гариза һәм мөрәҗәгать җибәргән, мәгълүмат биргән затлардан өстәмә мәгълүматлар һәм материаллар соратып алу буенча (шул исәптән телдән) чаралар күрелә, юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең муниципаль җир контроле органы карамагында булган документларын карап тикшерү үткәрелә, кирәк булганда әлеге затларга мәгълүмат бирү һәм муниципаль җир контроле органы таләпләрен үтәү буенча бурычлар йөкләмичә һәм юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән бәйләнешсез гамәлгә ашырыла торган контроль чаралар үткәрелә. Юридик затны, шәхси эшмәкәрне алдан тикшерү кысаларында, алынган мәгълүматка карата аңлатмалар соратып алынырга мөмкин, ләкин андый аңлатмаларны һәм башка документларны бирү мәҗбүри түгел.

Алдан тикшерү нәтиҗәләре буенча муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куйган зат турында 294-ФЗ номерлы «Юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең дәүләт контроле (күзәтүе) һәм муниципаль контроль башкарганда хокукларын саклау турында» Федераль законның 2нче өлеше, 7нче бүлеге 10нчы статьясы нигезендә дәүләт контроле (күзәтүе), муниципаль контроль органы вәкаләтле вазыйфаи заты «Юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең дәүләт контроле (күзәтүе) һәм муниципаль контроль башкарганда хокукларын саклау турында» Федераль законының 2нче өлеше, 7нче бүлеге 10нчы статьясында күрсәтелгәннәргә нигезләнеп планнан тыш тикшерү билгеләүне мотивлы тәкъдим итә. Алдан тикшерү нәтиҗәләре буенча юридик затны, шәхси эшмәкәрне җаваплылыкка тарту каралмаган.

Муниципаль җир контроле органы җитәкчесе, җитәкче урынбасары карары буенча, тиешле тикшерү башланганнан соң аны оештыруга сәбәп булган мөрәҗәгать яки гаризаның аноним булуы, яисә мөрәҗәгать яки гаризада дөрес булмаган мәгълүматлар барлыгы ачыкланса, ул вакытта алдан тикшерү, планнан тыш тикшерү туктатыла.

Әгәр гаризаларда, мөрәҗәгатьләрдә ялган мәгълүматлар күрсәтелгән булса, муниципаль җир контроле органы муниципаль җир контроле органының гражданнан, шул исәптән юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән күрсәтелгән затларның гаризаларын һәм мөрәҗәгатьләрен карауга бәйле чыгымнарын кайтарып алу турындагы дәгъва белән судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

2.3.1. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашырудагы тикшерүгә нәтиҗәлә ясау 30 эш көненнән дә артмый, ләкин административ регламентның 2нче абзацы 2нче пунктының 2.3.4.пункт астында күрсәтелгәннәр нигезендә озынайтылырга мөмкин.

2.3.2. Муниципаль җир контролен план буенча (документар яки күчмә) гамәлгә ашыру түбәндәге этаплардан тора:

- план буенча (документар яки күчмә) тикшерү үткәрү турында Палата боерыгын , план буенча тикшерелү үткәрелә торган затларга бу турыда хәбәрнамә әзерләү;

-план буенча 20 эш көненнән армаган тикшерү (документар яки күчмә) уздыру.

Бер кече эшмәкәрлек субъектына карата планлы күчмә тикшерүләр үткәрүнең гомуми срогы кече предприятие өчен елына – 50 сәгатьтән, микропредприятие өчен 15 сәгатьтән артырга тиеш түгел.

2.3.3.Тикшерү үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати үзара эшчәнлек кысаларында документлар һәм (яки) мәгълүмат алу кирәк булган очракта, тикшерү үткәрү муниципаль җир контроле органы җитәкчесе тарафыннан ведомствоара мәгълүмати үзара эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле срокка туктатып торылырга мөмкин, ләкин ун эш көненнән дә артык булырга тиеш түгел. Тикшерү үткәрүне кабаттан туктатып тору рөхсәт ителми.

Тикшерү үткәрүне туктатып тору срогы гамәлдә булган чорда территориядә, биналарда, төзелешләрдә, корылмаларда, бүлмәләрдә, башка кече эшмәкәрлек субъекты объектларында муниципаль җир контроле органының әлеге тикшерүгә бәйле эшләре туктатылып тора.

2.3.4. Планлы күчмә тикшерү үткәрә торган муниципаль җир контроле органы вазыйфаи затларының дәлилле тәкъдимнәре нигезендә катлаулы һәм (яки) озак тикшеренүләр, сынаулар, махсус экспертизалар һәм тикшерүләр үткәрү кирәклеге белән бәйле аерым очракларда, планлы күчмә тикшерү үткәрү срогы шундый орган җитәкчесе тарафыннан озайтылырга мөмкин, ләкин ул 20 эш көненнән дә артык була алмый, кече предприятиеләргә карата – 50 сәгатьтән, микропредприятиеләр өчен 15 сәгатьтән дә артык түгел.

2.3.5. Планлы булмаган муниципаль җир контролен (документар яки күчмә) гамәлгә ашыру 30 эш көненнән дә артмый һәм түбәндәге этаплардан тора:

- гражданнар, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләрдән мөрәҗәгатьләр, дәүләт хакимияте, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан административ регламентның 2нче абзацы 2.2нче пунктының 2.2..пункт астында күрсәтелгән фактлар турында мәгълүмат кабул итү һәм теркәү;

- - планнан тыш (документар яки күчмә) тикшерү үткәрү турында Палата боерыгын , гражданнар, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләргә карата планлы булмаган тикшерү үткәрүне прокуратура органы белән килештерү, тикшерелү үткәрелә торган затларга административ регламентның 1нче абзацы 3.4. нче пунктының 3.4.5.пункты белән билгеләнгән нигездә бу турыда хәбәрнамә

әзерләү;

- 20 эш көненнән дә артмаган планда булмаган (документар яки күчмә) тикшерү үткәрү.

2.3.6. Документар яки күчмә тикшерү нәтиҗәләре турында акт тикшерү тәмамлану белән рәсмиләштерелә. Әгәр акт төзү өчен үткәрелгән тикшерүләр, сынаулар, махсус тикшерүләр , экспертизалар нәтиҗәләрен алырга кирәк булса, акт тикшерү чаралары үткәннән соң 3 көн эчендә төзелә.

## III. Административ процедуралар.

3.1. Күчмә һәм (яки) документар планлы һәм планнан тыш муниципаль җир контроле түбәндәге эзлеклелектә башкарыла:

-тикшерүләрне планлаштыру;

- тикшерүләрне үткәрүгә әзерлек;

- Күчмә яки документар тикшерү үткәрү һәм нәтиҗәләрен рәсмиләштерү;

-тикшерүләр хисабын алып бару .

3.2. Тикшерүләрне планлаштыру

3.2.1. Планлы тикшерүләр Палата җитәкчесе раслаган еллык планлы тикшерүләр үткәрү планы буенча үткәрелә. юридик затка (аның филиалларына, вәкиллекләренә, аерым структур бүлекчәләренә) планлы тикшерү үткәрүнең еллык планында түбәндәгеләр күрсәтелә:

- планлы тикшерү үткәрү турында яки шәхси эшмәкәргә, гражданга тикшерү башланганчы өч эш көненнән дә соңга калмый, муниципаль җир контроле органы тарафыннан, планлы тикшерү башлану турында муниципаль җир контроле органы җитәкчесенең боерыгы (приказы) күчермәсен, почта аша тапшыру турында белдерү кәгазе булган заказлы хат һәм башка төрле уңайлы ысул белән җибәреп хәбәр ителә;

- юридик зат (аның филиаллары , вәкиллекләре , аерым структур бүлекчәләре ) атамалары, эшчәнлекләренә карата планлы тикшерү каралган шәхси эшмәкәрләрнең фамилияләре, исемнәре, әтиләренең исемнәре, юридик зат (аның филиаллары , вәкиллекләре , аерым структур бүлекчәләре ) урнашу урыны яки шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген алып бара торган фактик урын;

- һәр планлы тикшерү үткәрүнең максаты һәм бурычлары;

- һәр планлы тикшерүнең башлану вакыты һәм сроклары ;

- конкрет планлы тикшерү үткәрүче дәүләт контроле (күзәтүе) органы атамасы. Планлы тикшерү дәүләт контроле (күзәтүе) органы, муниципаль контроль органы тарафыннан уздырылса, тикшерүдә катнашучы бар органнарның да атамалары күрсәтелә.

3.2.2. Планлы тикшерүнең предметы булып юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан тарафыннан эшчәнлек алып бару процессында мәҗбүри таләпләр һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләр үтәлешен тикшерү тора.

Россия Федерациясе Хөкүмәте аерым төр дәүләт контроленә (күзәтүенә) карата 2008нче елның 26нчы декабрендә чыккан 294-ФЗ номерлы «Юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең дәүләт контроле (күзәтүе) һәм

муниципаль контроль башкарганда хокукларын саклау турында» Федераль законының 1нче һәм 2нче өлеше, 8.1нче статьясы нигезендә , юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлеге аерым хәтәр категориягә , аерым куркыныч класска кертелгән очракта мондый юридик зат, шәхси эшмәкәрне тикшерү үткәрелмәскә мөмкин.

3.2.3. Муниципаль җир контроле органы планлы тикшерүләр үткәрү елыннан алдагы елның 1 сентябренә кадәр срокта, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планын муниципаль җир контроле урнашкан урын буенча прокуратура органына җибәрә.

3.2.4. Планлы тикшерүне планга кертү өчен түбәндәгеләрдән соң өч ел үткән булу нигез булып тора:

1) юридик зат, шәхси эшмәкәр дәүләт теркәвенә алынганнан, гражданның җир мөнәсәбәтләре объектына (алга таба – җир участогы) хокуклары барлыкка килгәннән соң;

2) юридик затны, шәхси эшмәкәрне, гражданны соңгы планлы тикшерү үткәрү тәмамланганнан соң;

3) күрсәтелгән белдерү кәгазен бирүне таләп итә торган эшләр башкарылган яки хезмәтләр күрсәтелгән очракта, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең тиешле өлкәсендә вәкаләтләнгән федераль башкарма хакимият органына бирелгән эшмәкәрлек эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турындагы белдерү кәгазе нигезендә юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан эшмәкәрлек эшчәнлеге гамәлгә ашырыла башлаганнан соң .

3.3. Планлы тикшерүләр үткәрүгә әзерлек.

3.3.1 Планлы тикшерүләр үткәрүгә әзерлек түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- Палата тарафыннан планлы тикшерү үткәрү турында боерык әзерләү һәм имзалау;

- юридик зат, шәхси эшмәкәрне планлы тикшерү үткәрү турында хәбәрдар итү.

Палата тарафыннан юридик зат, шәхси эшмәкәргә карата планлы тикшерү үткәрү турында боерык әзерләгәндә боерыкның Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге 141 нче Приказы белән расланган типовой формасы кулланыла.

Палата җитәкчесе яки аның урынбасарының физик затка карата тикшерү билгеләү турындагы боерыгында түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) муниципаль җир контроле органы атамасы;

2) тикшерү үткәрәчәк вазыйфаи зат яки затларның, шулай ук тикшерүдә катнашучы экспертларның, эксперт оешмалары вәкилләренең вазыйфалары, фамилияләре, исемнәре, әтиләренең исемнәре;

3)тикшерү үткәреләчәк гражданинның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме;

4) тикшерү объекты булган җир кишәрлегенең идентификацион билгеләре (җир кишәрлегенең адресы яки падресы булмаганда урнашу урынының башкача тасвирламасы , аның кадастр номеры, җир кишәрлеге керә торган җирләрнең) ;

5) тикшерү үткәрүнең хокукый нигезләре;

6) тикшерү төре (планлы яки планнан тыш) һәм аны үткәрү формасы (документар яки күчмә);

7 ) гражданин тәкъдим итәргә тиешле документлар исемлеге;

8) тикшерүнең башлану һәм тәмамлану вакыты .

Әлеге подпунктта күрсәтелгән эшләрне башкаруга әлеге Палатаның эшләрне үз вазыйфаи инструкцияләре нигезендә башкаручы вазыйфаи затлары яки Палата Җитәкчесе яки аның урынбасары белән билгеләнгән вазыйфаи затлар җаваплы.

3.3.2. Әлеге эшләрнең нәтиҗәсе булып Палата Җитәкчесе яки аның урынбасары тарафыннан имзаланган планлы тикшерү турындагы боерык һәм шәхси эшмәкәргә бу турыда юлланган хәбәрнамә тора.

3.4. Планнан тыш тикшерүләр үткәрүгә әзерлек.

3.4.1. Планнан тыш тикшерүләр үткәрүгә әзерлек түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- гражданнар, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләрдән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар кабул итү һәм теркәү , дәүләт хакимияте , җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан административ регламентның 2нче абзацы 2.2нче пунктының 2.2..пункт астында күрсәтелгән фактлар турында мәгълүмат кабул итү һәм теркәү;

- әлеге административ регламентның 2.2. пункты , 2 пунктының а, ә абзацларында күрсәтелгән фактлар булу турында белешмә булу;

- Палата тарафыннан планлы тикшерү үткәрү турында боерык әзерләү һәм имзалау;

- планнан тыш (документар яки күчмә) тикшерү үткәрү турында Палата боерыгын , гражданнар, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләргә карата планлы булмаган тикшерү үткәрүне прокуратура органы белән килештерү;

- тикшерелү үткәрелә торган затларга бу турыда хәбәрнамә әзерләү һәм юллау.

3.4.2. Әлеге административ регламентның 3.4. пунктының 3.4.1 подпунктында күрсәтелгән эшләрне башкаруга әлеге Палатаның эшләрне үз вазыйфаи инструкцияләре нигезендә башкаручы вазыйфаи затлары яки Палата Җитәкчесе яки аның урынбасары белән билгеләнгән вазыйфаи затлар җаваплы.

3.4.3. Әлеге административ регламентның 3.4. пунктының 3.4.1 подпунктында күрсәтелгән эшләрне башлауга нигез Палата Җитәкчесе яки аның урынбасары визасы (кушуы) буенча гражданнар, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләрдән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар кабул итү һәм теркәү , дәүләт хакимияте, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан административ регламентның 2нче абзацы 2.2нче пунктының 2.2..пункт астында күрсәтелгән фактлар турында мәгълүмат кабул итү тора.

3.4.4. Әгәр вазыйфаи зат тарафыннан гариза, мөрәҗәгать, шикаятьтә административ регламентның 2.2. пункты , 2 пунктының а, ә абзацларында күрсәтелгән фактлар булмаса, Палатаның вазыйфаи заты:

- мөрәҗәгать иткән затка гаризаны карауны кире кагуның сәбәпләрен күрсәтеп җавап (хат) проекты әзерли (алга таба - җавап (хат);

- җавап (хат) проектын имзалау өчен Палата Җитәкчесе яки аның урынбасары тапшыра;

- Палата Җитәкчесе яки аның урынбасары имзалаган - җавап (хат)ны мөрәҗәгать иткән затка җибәрә.

Палата тарафыннан юридик зат, шәхси эшмәкәргә карата планлы тикшерү үткәрү турында боерык әзерләгәндә боерыкның Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге 141 нче Приказы белән расланган типик формасы кулланыла.

3.4.5. Муниципаль контроль органы җитәкчесе, юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында боерык (приказ) имзалаган көнне, аны үткәрүне федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә килешенү максатында, муниципаль җир контроле органы юридик затның, шәхси эшмәкәрнең эшчәнлек алып бару урыны буенча прокуратура органына планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килешенү турындагы гаризаны тапшыра яисә почта аша тапшыру турында белдерү кәгазе булган заказлы хат, яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрә. Әлеге гаризага муниципаль җир контроле органы җитәкчесенең планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турындагы боерыгының яки приказының күчермәсе һәм аны үткәрү өчен нигез булып хезмәт итә торган документлар теркәлә.

Әгәр планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү өчен нигез булып гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян килү, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, дәүләт иминлегенә зыян килү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу, андый кимчелекләр булу вакытына мәҗбүри таләпләрнең һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең бозылуы ачыклану торса, 294-ФЗ номерлы «Юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең дәүләт контроле (күзәтүе) һәм муниципаль контроль башкарганда хокукларын саклау турында» Федераль законының 6-7нче бүлеге 10нчы статьясы нигезендә кичектергесез чаралар күрү кирәк булу сәбәпле, муниципаль җир контроле органы 24 сәгать эчендә прокуратура органнарына документлар җибәрү юлы белән прокуратура органнарына контроль чаралар үткәрү турында хәбәр итеп, кичемәстән планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүгә керешергә хокуклы. Бу очракта прокурор яки аның урынбасар планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турындагы карарны тиешле документлар кергән көнне үк кабул итә.

3.4.5. Әлеге эшләрне башкаруның нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

- Палата Җитәкчесе яки аның урынбасары тарафыннан имзаланган планнан тыш документар яки күчмә тикшерү турындагы боерыкны имзалау;
- Палата Җитәкчесе яки аның урынбасары тарафыннан административ регламентның 2нче абзацы 2.2нче пунктының 2.2..пункт астында күрсәтелгән фактлар турында мөрәҗәгать, гариза, шикаять кабул итүгә дәлилле җавапны имзалау;
- - юридик зат, шәхси эшмәкәрне планнан тыш тикшерү үткәрү турында хәбәрдар итү.

3.5. Документар яки күчмә тикшерү үткәрү һәм нәтиҗәләрен рәсмиләштерү.

3.5.1. Документар яки күчмә тикшерү үткәрү Палатаның Документар яки

күчмә тикшерү үткәрү турындагы боерыгы нигезендә башкарыла.

3.5.2. Тикшерүне үткәрү Палатаның вазыйфаи заты тарафыннан Палатаның тикшерү үткәрү турындагы боерыгы нигезендәге вәкаләтләре буенча башкарыла.

3.5.3. Документар тикшерү Палата урнашкан урында үткәрелә.

Документар тикшерү барышында Палатаның вазыйфаи заты беренче чиратта, Палата карамагында булган тикшерү үткәрелә торган зат документларын , шулай ук әлеге затлар куллана торган җир кишәрлекләре документларын, алдагы тикшерү актларын , административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау материалларын, һәм бу затларга карата башкарылган башка муниципаль контроль документларын карый.

Палата карамагында булган документлардагы мәгълүматларның дөреслеге нигезле шик уятса яки алар юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик зат тарафыннан мәҗбүри шартларны яки муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән мәҗбүри шартлар үтәүне бәяләргә мөмкинлек бирми икән, Палата аларга документар тикшерү барышында карау өчен кирәк булган, 10 көн эчендә җибәрелергә тиешле документлар исемлеген юллый . Запроска Палата боерыгының мөхер белән расланган копиясе дә теркәлә.

Документар тикшерү барышында юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик зат тарафыннан җибәрелгән документларда хаталар һәм (яки) каршылыклар , я булмаса Палатада булган документлар белән туры килмәүләр килеп чыкса, Палата бу турыда юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик затка 10 көн эчендә ачыклык кертүче аңлатмалар җибәрүне сорап мәгълүмат юллый.

Документар тикшерү үткәрүче вазыйфаи зат юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик зат тарафыннан җибәрелгән алдан бирелгән документларның дөреслеген раслаучы аңлатмаларны карарга тиеш. Әгәр бу аңлатмалар булмаса, яисә аларны караганнан соң муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән мәҗбүри шартларны бозу ачыкланса, муниципаль контроль органы вазыйфаи заты күчмә тикшерү үткәрергә хокуклы.

Документар тикшерү үткәргәндә тикшерүченең юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән, гражданнан документар тикшерү предметына карамаган, шулай ук башка дәүләт контроле органнарыннан алырга мөмкин булган документларны һәм (яки) мәгълүматны тапшыруны таләп итүгә хокукы юк.

3.5.4. Күчмә тикшерү юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик зат эшчәнлеген алып бара торган урында, аерым алганда юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик зат файдалана торган җир кишәрлегендә алып барыла.

Палата вазыйфаи заты тикшерүне хезмәт таныкнамәсен күрсәтүдән башлый, юридик зат, шәхси эшмәкәрнең җитәкчесе яки башка вәкаләтле вәкилен Палатаның күчмә тикшерү турындагы боерыгы белән, Палатаның башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан ведомствоара мәгълүматый хезмәттәшлек чикләрендә алган документлары һәм (яки) мәгълүмат, шулай ук күчмә тикшерүнең максаты,бурычлары, үткәрү нигезе , тикшерү төрләре һәм күләме, күчмә тикшерү вәкилләре , үткүрү вакыты һәм шартлары белән таныштыра.

Юридик зат, шәхси эшмәкәрнең җитәкчесе яки башка вәкаләтле вәкиле Палатага үз инициативасы белән ведомствоара мәгълүматый хезмәттәшлек

чикләрендә сорала торган документлар һәм (яки) мәгълүмат бирә ала.

Тикшерү барышында дәүләт контроле органы вазыйфаи затлары түбәндәгеләргә хокуксыз:

- әгәр андый таләпләр дәүләт контроле органы дәүләт контроле органы исеменнән эш итүче әлеге вазыйфаи затларның вәкаләтләренә кермәсә, мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәүне тикшерү;

- СССР һәм РСФСР башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләрне үтәүне, шулай ук Россия Федерациясе законнарында мәҗбүри куллану каралмаган норматив документларның таләпләрен үтәүне тикшерү;

- мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне, Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә бастырып чыгарылмаган таләпләрне үтәүне тикшерү;

- планлы һәм планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыру, әгәр җитәкче, башка вазыйфаи зат яки юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле, граждан яки аның вәкиле тикшерүдә катнашмаган очракта, андый тикшерү 294-ФЗ санлы Федераль 13 законның 10 маддәсе 2 бүлеге 2 пунктының «б» пункт астында каралган нигездә үткәрелгән очрактан тыш, шулай ук җир участоклары милекчеләренә, җирдән файдаланучыларга, җир хуҗаларына һәм җир участоклары арендаторларына тиешенчә хәбәр җиткерелгән очракта, җир законнары таләпләрен үтәүне тикшерү;

- тикшерү объектлары булып саналмаган яки тикшерү предметына карамаган документларны, мәгълүматны, продукция үрнәкләрен, әйләнә- тирә мохит объектларын һәм производство объектларын тикшерү пробаларын тапшыруны таләп итү, шулай ук андый документларның төп нөсхәләрен куллanудан алу;

- илкүләм стандартлар, үрнәкләр, пробалар сайлап алу кагыйдәләре һәм аларны тикшерү, сынау, үлчәү методлары, техник регламентлар яки аларның үз көченә керү көненә кадәрге башка норматив техник документлар һәм тикшерү, сынау, үлчәү методлары һәм кагыйдәләре белән билгеләнгән нормалардан артып киткән һәм билгеләнгән форма буенча күрсәтелгән үрнәкләрне, пробаларны сайлап алу турында беркетмәләр рәсмиләштермичә, аларны тикшерү, сынау, үлчәүне үткәрү өчен әйләнә- тирә мохит объектларын һәм производство объектларын тикшерү пробаларын, продукция үрнәкләрен алу;

- тикшерү үткәрү нәтиҗәләрендә алынган һәм дәүләт, коммерция, хезмәт буенча һәм башка закон белән саклана торган сер булган (Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш) мәгълүматны тарату;

- тикшерү үткәрүнең билгеләнгән срокларын арттыру;

- юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, гражданнарга контроль чараларны алар хисабына үткәрү турында күрсәтмәләр һәм тәкъдимнәр бирүне гамәлгә ашыру;

- юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән, гражданнардан, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары буйсынуындагы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан

аерым исемлеккә кертелгән оешмалар карамагындагы рөхсәт бирү документларын да кертеп, документлар һәм (яки) мәгълүматлар таләп итү;

- - күчмә тикшерү үткәргәндә, юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән, гражданнан документар тикшерү барышында алар тарафыннан тапшырылган документларны һәм (яки) мәгълүмат тапшыруны таләп итү, юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән, гражданнан тикшерү үткәрә башлау датасына кадәр документлар, мәгълүматлар тапшыруны таләп итү.

Муниципаль җир контроле органы тикшерү үткәрү турында боерык яки приказ кабул ителгәннән соң ведомствоара мәгълүмати эшчәнлек кысаларында кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматны соратып алырга хокуклы.

3.5.1. Документар яки күчмә тикшерү 20 эш көненән дә артыкка сузыла алмый.

Бер кече эшмәкәрлек субъектына карата планлы күчмә тикшерүләр үткәрүнең гомуми срогы кече предприятие өчен елына – 50 сәгатьтән, микропредприятие өчен 15 сәгатьтән артырга тиеш түгел.

Тикшерү үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати үзара эшчәнлек кысаларында документлар һәм (яки) мәгълүмат алу кирәк булган очракта, тикшерү үткәрү муниципаль җир контроле органы җитәкчесе тарафыннан ведомствоара мәгълүмати үзара эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле срокка туктатып торылырга мөмкин, ләкин ун эш көненнән дә артык булырга тиеш түгел. Тикшерү үткәрүне кабаттан туктатып тору рөхсәт ителми.

Тикшерү үткәрүне туктатып тору срогы гамәлдә булган чорда территориядә, биналарда, төзелешләрдә, корылмаларда, бүлмәләрдә, башка кече эшмәкәрлек субъекты объектларында муниципаль җир контроле органының әлеге тикшерүгә бәйле эшләре туктатылып тора.

Дәүләт контроле (күзәтүе) органы, муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының дәлилле тәкъдимнәре нигезендә искәрмә рәвештә аерым очракларда, катлаулы һәм (яки) озак тикшеренүләр, сынаулар, махсус экспертизалар һәм тикшерүләр үткәрү кирәклеге белән бәйле аерым очракларда, планлы күчмә тикшерү үткәрү срогы шундый орган җитәкчесе тарафыннан озайтылырга мөмкин, ләкин ул 20 эш көненнән дә артык була алмый, кече предприятиеләргә карата – 50 сәгатьтән, микропредприятиеләр өчен 15 сәгатьтән дә артык түгел.

3.5.2. Палатаның вазыйфаи заты тарафыннан юридик зат, шәхси эшмәкәргә карата тикшерү үткәрү нәтиҗәләре турында акт төзегәндә Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге 141 нче Приказы белән расланган типик акт формасы кулланыла

3.5.2.Палатаның вазыйфаи заты тарафыннан төзелгән әлеге актта түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) акт төзү датасы, вакыты, урыны;

2) муниципаль җир контроле органы атамасы;

3) муниципаль җир контроле органы җитәкчесенең (урынбасаының) тикшерү билгеләү турындагы боерыгы (приказы) чыккан дата һәм номеры;

4) тикшерү уздырган вазыйфаи зат яки затларның фамилия, исем , әтисе исемнәре һәм вазифасы;

5) тикшерү үткәрелгән гражданинның фамилия, исем , әтисе исеме;

6) тикшерү барышында һәм акт төзегәндә катнашкан затларның фамилияләре, исемнәре , әтисе исемнәре һәм вазифалары;

7) тикшерүнең башлану һәм төгәлләнү даталары һәм вакыты;

8) тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат, шул исәптән Россия Федерациясе канунчылыгын, Татарстан Республикасы канунчылыгын ачыкланган бозу очраклары;

9) тикшерүдә катнашкан гражданин яки аның вәкиленең тикшерү актында күрсәтелгәннәр белән танышу яки танышырга теләмәү турында мәгълүмат, аларның имзалары яки имза куюга каршы килүләре турында мәгълүматлар;

10) тикшерү уздырган вазыйфаи зат яки затларның имзалары.

Тикшерү актына үткәрелгән тикшеренү эшләре һәм экспертизаларның белешмәләре, юридик зат, шәхси эшмәкәрнең муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән мәҗбүри шартларны үтәү өчен җаваплы хезмәткәренең аңлатмалары, ачыкланган кимчелекләрне бетерү турында күрсәтмәләр һ.б. тикшерү нәтиҗәләре белән бәйле документлар яки аларның күчермәләре (фототаблица, җир кишәрлеге мәйданы һ.б.)

Тикшерү акты тикшерү тәмамланганнан соң ике нөсхәдә төзелә һәм бер нөсхәсе (кушымталары белән бергә) тикшерү акты белән танышу яисә танышудан баш тарту турындагы расписка белән җитәкчегә, юридик затның башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә, гражданга яки аның вәкиленә тапшырыла. Җитәкче, юридик затның башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле, граждан яки аның вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелә торган зат тикшерү акты белән танышу турында яисә танышудан баш тарту турында расписка бирүдән баш тарткан очракта, акт почта аша аны тапшыру турында белдерү кәгазе булган заказлы хат җибәрелә һәм делода саклана торган акт нөсхәсенә теркәп куела. Тикшерелүче затның электрон формада хезмәттәшлеккә ризалыгы булган очракта акт аны төзүченең көчәйтелгән электрон имзасы белән җитәкчегә, башка вәкаләтле вәкилгә электрон документ рәвешендә җибәреләргә мөмкин. Бу рәвешле җибәрелгән тикшерү акты тикшерелүче зат тарафыннан алынган дип санала.

Тикшерү акты төзү өчен махсус үткәрелгән тикшерүләрнең, экспертизаларның нәтиҗәләре кирәк булса, тикшерү акты контроль чаралары тәмамланганнан соң 3 көн эчендә төзелә һәм җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки юридик зат, шәхси эшмәкәрнең вәкаләтле вәкиленә, физик затка расписка буенча , я булмаса тапшыру турында хәбәрнамәле заказлы хат белән тапшырыла, яисә (яки) әлеге актны төзүченең көчәйтелгән имзасы белән электрон документ рәвешендә (тикшерелгән затның дәүләт контроле (күзәтүе) яки муниципаль контроль чикләрендә бәйләнешләрне электрон формада башкаруга ризалыгы булган очракта), әлеге документны алуны раслаучы ысул белән. Бу вакытта тапшыру турында хәбәрнамә яки күрсәтелгән документны алуны раслаучы башка ысул Палатада саклана торган эштәге тикшерү актына өстәлә.

Әгәр планнан тыш тикшерү үткәрү өчен, аны прокуратура органы белән

килештерергә туры килсә, тикшерү акты копиясе килештерү башкарылган прокуратура органына акт төзелгәннән соң биш эш көне эчендә юллана.

Дәүләт, коммерция, хезмәт, башка сер турында мәгълүмат кергән тикшерү акты Россия Федерациясе канунчылыгы шартлары нигезендә рәсмиләштерелә. Юридик затларда, шәхси эшмәкәрләрдә тикшерүләр хисабын алып бару журналы булса, Палатаның вазыйфаи затлары тарафыннан анда муниципаль контроле органы атамасы, акт төзү датасы, вакыты, урыны, хокукый нигезләре, максаты, бурычлары, тикшерү предметы, тикшерү уздырган вазыйфаи зат яки затларның фамилия, исем , әтисе исемнәре һәм вазифасы, аларның имзалары белән үткәрелгән тикшерү турында язма булдырыла.

Тикшерүләр хисабын алып бару журналы булмаса, мондый язма тикшерү актына языла.

3.5.3. Тикшерү үткәрелгәннән соң 5 эш көне эчендә Палата тикшерү материалларын, документларны карау һәм җир канунчылыгын бозучыга карата тиешле чаралар күрү өчен җирләрне куллану һәм саклауны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтле органга тикшерүгә җибәрә.

3.5.4. Актның кушымта күчермәләре белән бер нөсхәсе җитәкчегә, җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки юридик зат, шәхси эшмәкәрнең вәкаләтле вәкиленә, физик затка расписка буенча , я булмаса тапшыру турында хәбәрнамәле заказлы хат белән тапшырыла, яисә (яки) әлеге актны төзүченең көчәйтелгән имзасы белән электрон документ рәвешендә (тикшерелгән затның дәүләт контроле (күзәтүе) яки муниципаль контроль чикләрендә бәйләнешләрне электрон формада башкаруга ризалыгы булган очракта), әлеге документны алуны раслаучыысул белән. Бу вакытта тапшыру турында хәбәрнамә яки күрсәтелгән документны алуны раслаучы башка ысул Палатада саклана торган эштәге тикшерү актына өстәлә.

3.5.5. Планлы яки планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле, юридик затның җитәкчесе яки башка вазыйфаи заты булмау, яки шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле, юридик затның җитәкчесе яки башка вазыйфаи затының тикшерү үткәрергә мөмкинлек бирми торган башка гамәлләре (эш итмәве) аркасында мөмкин булмаса, муниципаль контроль органы вазыйфаи заты тиешле тикшерүне үткәреп булмавы турында сәбәпләрен күрсәтеп акт төзи. Бу очракта тикшерүне үткәреп булмавы турында акт төзелгәннән соң муниципаль контроль органы мондый юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик затка карата еллык планлы тикшерүләр планына кертмичә һәм юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик затка алдан хәбәр бирмичә, планлы яки планнан тыш күчмә тикшерү уздыруга хокуклы.

## IV. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрү функцияләрен тикшерү

4.1. Муниципаль җир контроле органы вазыйфаи затларның хезмәт бурычлары үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыра, тикшерүләр үткәрү барышында вазыйфаи затларның үз вәкаләтләрен тиешенчә башкармау очракларының исәбен алып бара, тиешле тикшерүләр үткәрә һәм вазыйфаи затларга карата Россия Федерациясе законнары нигезендә чаралар күрә.

4.2. Әлеге Регламентның үтәлешен контрольдә тоту муниципаль җир контроле органы җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Муниципаль җир контроле органының муниципаль функцияне үтәү тулылыгына һәм сыйфатына контроль планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрүне, тикшерелә торган затларның хокукларын бозуларны ачыклау һәм бетерүне, муниципаль җир контроле органы вазыйфаи затларының эш итүләренә (эш итмәүләренә) карата гариза биргән затларның мөрәҗәгатьләрен карау, карарлар кабул итү һәм җаваплар әзерләүгә контрольне дә үз эченә ала.

4.4. Үткәрелгән тикшерүләрнең нәтиҗәләре буенча, муниципаль җир контроле органы вазыйфаи затларының муниципаль функцияне үтәгәндә җибәргән кимчелекләре ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

## V. Муниципаль функцияне үтәүче вазыйфаи затларның карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирү тәртибе

5.1. Гариза бирүче затлар муниципаль җир контроле тикшерүе барышында вазыйфаи затларының эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирү хокукы бар.

5.2. Вазыйфаи затларының эш итүләренә (эш итмәүләренә), карарларына шикаять (алга таба - шикаять) бирү телдзн мөрәҗәгать формасында да, язма формада да булырга мөмкин.

5.3. Җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка электрон формада җибәрелгән мөрәҗәгатькә җавап 2006нчы елның 2нче маендагы 59-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законы нигезендә карала. Мөрәҗәгатьтә гражданин мәҗбүри рәвештә фамилиясен, исемен, әтисенең исемен (соңгысын - булган очракта), җавап, башка адреска җибәрү турында хәбәрнамә җибәрелергә тиешле электрон почта адресын күрсәтә. Гражданин мондый мөрәҗәгатькә электрон формада кирәкле документлар һәм материалларны теркәүгә хокуклы.

5.4. Гариза бирүче язмача шикаятьтә мәҗбүри рәвештә шикаять җибәрә торган җирле үзидарә органының атамасын, яки вазыйфаи затның фамилиясен, исемен, әтисенең исемен , яки вазыйфаи затның вазыйфасын, шулай ук үзенең фамилиясен, исемен, әтисенең исемен, җавап, шикаять башка адреска җибәрелү турында хәбәрнамә җибәрелергә тиешле почта адресын күрсәтә, шикаятьнең төп эчтәлеген бирә, шәхси имзасын һәм датаны куя.

Кирәк булган очракта гариза бирүче язмача шикаятькә үзенең дәлилләрен раслаучы документлар һәм материаллар яки аларның копияләрен терки.

5.5. Язмача шикаять яки шикаять теркәгәннән соң 30 эш көне эчендә каралырга тиеш. Шикаятьтә күтәрелгән мәсьәләләрне чишү өчен артыграк вакытлар кирәк булган ерым очракларда карау вакыты озынайтылырга мөмкин, ләкин 30 көннән дә артыкка түгел, бу турыда шикаять бирүчегә карау вакыты озынайтылуның сәбәпләренаңлатып язма формада җавап бирелә.

5.6. Җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка электрон формада җибәрелгән мөрәҗәгатькә җавап мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча электрон документ формасында җибәрелә, һәм җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка язма формада килгән мөрәҗәгатькә җавап мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән почта адресы буенча язма формада җибәрелә. Моннан тыш, җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка кергән мөрәҗәгатьтә аерым затлар мәнфәгатьләренә карый торган тәкъдим, гариза яки шикаять, аерым алганда мөрәҗәгать аерым затларга карата чыгарылган суд карарын яңадан карауны сораса, җавап, шул исәптән суд карарын кире яңадан тәртибен аңлатып, 2006нчы елның 2нче маендагы 59-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законның 2өлеше 6ст. нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муни-ципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында урнаштырылырга мөмкин.

5.7. Вазыйфаи затларның муниципаль җир контролен гамәлгә куйганда чыгарган карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судларга һәм арбитраж судларга шикаять бирү тәртибе Россия Федерациясендә гражданнар суд эшчәнлеге һәм арбитраж суд эшчәнлеге турындагы канунчылыгы белән билгеләнә.

5.8. Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, башка дәүләт яки икенче төрле вәкаләтләр бирелгән органнар һәм оешмаларның, вазыйфаи затларның, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрнең эш итүләренә (эш итмәүләренә) карата яңадан карау административ эшләрен карау тәртибе Россия Федерациясенең 2015нче елның 8нче мартындагы «Россия Федерациясендә административ суд эшчәнлеге Кодексы» белән билгеләнә.

## VI. 2019 – 2020нче елларда кече эшмәкәрлек субъектларына карата дәүләт контроле (күзәтүе) һәм муниципаль контроль оештыру һәм үткәрү үзенчәлекләре.

6. 2007нче елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә кече һәм уртача эшмәкәрлек үсеше турында» Федераль законының 4ст. белән кече эшмәкәрлек субъектларына кертелгән юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне план буенча тикшерү 2019нчы елның 1нче гыйнварыннан 2020нче елның 31нче декабренә кадәр үткәрелми. Моңа түбәндәге тикшерүләр керми:

1) юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлеге аерым хәтәр категориягә , аерым куркыныч класска кертелгән эшчәнлек, шулай ук юридик зат, шәхси эшмәкәрэшчәнлеге яки алар куллана торган производство объектлары аерым куркыныч класска (категориягә) кертелгәндә план буенча тикшерү;

2) Әлеге Федераль законның 9өлеше, 9ст. нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгели торган исемлектәге эшчәнлек төрләре белән шөгыльләнүче юридик затларны, шәхси эшмәкәрне план буенча тикшерү;

Россия Федерациясе Хөкүмәте аерым төр дәүләт контроленә (күзәтүенә)

карата 2008нче елның 26нчы декабрендә чыккан 294-ФЗ номерлы «Юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең дәүләт контроле (күзәтүе) һәм муниципаль контроль башкарганда хокукларын саклау турында» Федераль законының 1нче һәм 2нче өлеше, 8.1нче статьясы нигезендә, юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлеге аерым хәтәр категориягә , аерым куркыныч класска кертелгән очракта мондый юридик зат, шәхси эшмәкәрне тикшерү үткәрелмәскә мөмкин.

3) юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне план буенча дәүләт контроле (күзәтүе) органы, муниципаль контроль органында әлеге затларга карата элегрәк “Россия Федерациясендә административ хокук бозулар турындагы Кодексы” нигезендә билгеләнгән җитди хокук бозу өчен законлы көченә кергән административ җәза бирү турында карар чыгарылуы яки эшчәнлекне дисквалификацияләү яки административ туктатып тору, я булмаса 2011нче елның 4нче маендагы 99-ФЗ номерлы «Аерым төр эшчәнлекне лицензияләү турында» Федераль законы нигезендә лицензиясен гамәлдән чыгару билгеле булса, мондый карар чыгарылган тикшерүдән соң 3елдан азрак вакыт үткән булса;

4) лицензия бирелә торган эшчәнлек төре белән шөгыльләнә торган юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне план буенча тикшерүләр;

5) түбәндәге чикләрдә үткәрелә торган план буенча тикшерүләр :

а) радиацион куркынычсызлык тәэмин итү өлкәсендә федераль дәүләт күзәтүе;

б) дәүләт сере саклауны тәэмин итү өлкәсендә федераль дәүләт күзәтүе;

в) 2008нче елның 30 декабрендәге 307-ФЗ номерлы «Аудиторлык эшчәнлеге турында» Федераль законыбелән билгеләнгән аудитор оешмаларның эш сыйфатын тышкы тикшерү ;

г) атом энергиясе куллану өлкәсендә федераль дәүләт күзәтүе;

д) федераль дәүләт пробир күзәтүе.

6.1. Әлеге статьяның шартларын бозып планлы тикшерү үткәрү дәүләт контроле һәм муниципаль контроль үткәрү турында канунчылыкны бозу була һәм 2008нче елның 26декабрендәге 294-ФЗ номерлы «Юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең дәүләт контроле (күзәтүе) һәм муниципаль контроль башкарганда хокукларын саклау турында» Федераль законның 1нче өлеше 20ст. нигезендә тикшерү нәтиҗәләренең дөрес түгел дип саналуына китерә.